**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

05.09.2013 505-п

Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянырга кирәк.

3. Мәгълүмати-геологик ресурслар һәм геологик мониторинг бүлеге башлыгы В.Л.Полушинга әлеге Регламентны Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы субпорталында урнаштырырга.

4. Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы В.А.Тронинга әлеге боерыкның дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның җир асты байлыкларыннан файдалану буенча урынбасары Т.М. Акчуринга йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
05.09.2013 № 505-п боерыгы
белән расланды

## Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.
1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затлар: юридик һәм физик затлар, шәхси эшкуарлар (алга таба – Мөрәҗәгать итүче).
1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

13.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан шәһәре, Павлюхин ур., 75.

Министрлыкның эш графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 дан 18.00 гә кадәр, җомга 9.00 дан 16.45 кә кадәр, төшке аш 12.00 дән 12.45 кадәр.

Җәмәгать транспортында «Павлюхин» тукталышына кадәр килергә кирәк:
- 3, 4, 5, 12, 25, 27, 31, 37, 43, 47, 67, 69, 69а, 74, 74а, 77, 85 номерлы автобуслар; - 6, 12 номерлы троллейбуслар.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

13.2. Министрлыкның гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоны: 267-68-92. Электрон почта адресы: Tatyana.Vasileva@tatar.ru; Nataliya.Chuykova@tatar.ru.

1.33. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.eco.tatarstan.ru. Электрон почта адресы: eco@tatar.ru.

13.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.eco.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында

(http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә бәйле мәгълүматлар Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында Бүлек белгече урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Су кодексы (2012 елның 28 июлендәге ред.) (алга таба – РФ Су кодексы) («РФ законнары җыентыгы», 05.06.2006, № 23, 2381 ст., «Парламентская газета», № 90-91, 08.06.2006, «Российская газета», №121, 08.06.2006);

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 30.03.1999 ел, №52-ФЗ федераль закон (алга таба – 52-ФЗ номерлы федераль закон) («РФ законнары җыентыгы», 05.04.1999, № 14, 1650 ст., «Российская газета», № 64-65, 06.04.1999);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, №210-ФЗ федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон («Российская газета», №168, 30.07.2010, РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, ОФЗ 1, 417 ст.);

«Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчәргә яраклы суүткәргечләрнең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» (алга таба – СанПиН 2.1.4.1110-02) «Российская газета», № 81, 08.05.2002, «Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене», №19, 13.05.2002; «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитар кагыйдәләре (алга таба – СП 2.1.5.1059-01) («Российская газета», №172, 05.09.2001, «Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене», № 38, 17.09.2001);

«Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – 30.07.2012 ел, №646 Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары редакциясендә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы», 24.04.2012, №31, 0963 ст.);

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» (алга таба – 325 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 27.07.2005, №28, 0654 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, №46, 2144 ст.);

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

Су объекты – табигый яки ясалма сулык, су агымы яки су режимының характерлы формалары һәм билгеләре булган суларның даими яки вакытлыча туплануы булган бүтән объект;

Санитар саклык зоналары – су белән тәэмин итү чыганагын һәм/яки сусүткәргечне, башка объектны үз эченә алган территория. Санитар саклык зонасы хуҗалык эшчәнлегенең һәм саклауның махсус режимнары билгеләнә торган пояслардан тора;

Санитар саклык зонасында режим булдыру һәм тәэмин итүнең төп максаты булып су белән тәэмин итү чыганакларын һәм сусүткәргеч корылмаларын, шулай ук алар урнашкан территорияләрне санитар саклау тора.

Санитар саклык зонасы өч пояс составында оештырыла:

Санитар саклык зонасының беренче поясы (катгый режим) су алу җайланмалары урнашкан территорияне, барлык су үткәрү корылмаларының һәм су үткәрү каналының урнашу мәйданчыгын үз эченә ала. Аның максаты – су алу урынын һәм су алу корылмаларын очраклы яки аңлы рәвештә пычратудан һәм зарарланудан саклау.

Икенче пояс (чикләүләр поясы яки микроблы пычрану зонасы) гидродинамик исәп-хисап юлы белән билгеләнә һәм су белән тәэмин итү чыганакларының пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала. Икенче пояс суның су алу җайланмасына кадәр микроблар белән пычрану вакытын исәпкә ала.

Өченче пояс (химик пычрану зонасы) аннан читтә сулы горизонтка тотрыклы рәвештә химик пычраклар килеп торса, ул вакытта алар су алу корылмасының туклану өлкәсеннән читтә булуы яисә эксплуатация чорының исәпләнгән вакыты беткән вакыттан да иртәрәк булмаган чорда килеп җитүе шарты белән, гидродинамик исәп-хисаплар белән билгеләнә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбенең атамасы | Стандарт таләпләре эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
| --- | --- | --- |
| 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы | санитар саклык зоналары проектларын раслау<br>Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының | РФ Су кодексының 43 статьясындагы 2 өлеше;<br>№ 52-ФЗ федераль законның 8 ст. 4 п.;<br>СанПиН 2.1.4.1110-02 кагыйдәләренең 1.13 п.;<br>2177 номерлы ТР МК карарының 1 п.;<br>325 номерлы ТР МК карарының 3.3.10 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | 2177 номерлы ТР МК карарының 2 п.;<br>325 номерлы ТР МК карарының 3.3.10 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Санитар саклык зонасы проектын раслау турында Министрлык боерыгы (алга таба – Боерык) яисә санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турында хат. Боерыкта күрсәтелә:<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган юридик, физик зат яисә шәхси эшкуарның исеме, санитар саклык зонасы проектының исеме, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе номеры; | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 177 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибенең 1 пункты |
| | санитар саклык зонасы чикләренең урнашу урыны һәм күләме;<br>санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы;<br>территорияләрендә санитар саклык зонасы оештырыла торган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләренә тәкъдимнәр, түбәндәгеләр буенча:<br>су алу корылмаларының санитар саклык зоналары турында, санитар саклык зонасы чикләрендә территориядән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;<br>территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру | |

| | | |
|---|---|---|
| | проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Санитар саклык зонасы проекты мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге регламентның 2.5 һәм 2.6 пунктларында каралган документлар комплекты тапшырылганнан соң яисә ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында дәүләт органнарыннан соратылган документлар алынган көннән соң биш көн эчендә Боерык белән раслана.<br>Министрлык боерык чыккан көннән соң өч эш көне эчендә аның күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә һәм территорияләрендә санитар саклык зоналары оештырыла торган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларына җибәрә. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 177 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибенең 11 пункты |

Вакыты эш көннәрендә исәпләнә.

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Закон яки башка төрле норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | Санитар саклык зонасы проектын раслау өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1. ирекле рәвештә гариза, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:<br>а) юридик затлар өчен – тулы һәм кыскартылган исеме, оешу-хокук формасы, җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, урнашу урыны адресы, телефон, факс; физик затлар, шәхси эшкуарлар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесне раслаучы документ белешмәләре, яшәү урыны, телефон;<br>б) эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектының (алга таба – су объекты) атамасы һәм урнашу урыны, су объектыннан файдалану хокукын раслый торган документ реквизитлары (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия, судан файдалану шартнамәсе);<br>2. эшләнгән санитар саклык зонасы проекты;<br>3. өч пояс чикләрендә санитар саклык зонасы территориясенең санитар торышын яхшырту һәм чыганакның пычрануын кисәтү буенча территориясендә санитар саклык зоналары оештырыла торган муниципаль берәмлек башкарма комитеты һәм җирдән файдаланучылар белән килештерелгән, муниципаль берәмлек башкарма комитеты белән килештерелгән чаралар планы (үтәү чорларын, җаваплы башкаручыларны һәм финанслау | СанПиН 2.1.4.1110-02 кагыйдәләренең 1.12 п.; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 177 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибенең 3 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | чыганакларын билгеләүне күрсәтеп);<br>4. Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән су объектының беренче санитар саклык зонасы поясы өчен җир кишәрлеген файдалануга бирү турында документ күчермәсе;<br>5. су объектының санитар саклык зоналары чикләре төшерелгән картографик материал<br>Документлар күчермәләре билгеләнгән тәртиптә расланырга тиеш.<br>Нотариуста расланган документларның күчермәләре бер үк вакытта оригиналын күрсәтеп тапшырыла.<br>Документлар санитар саклык зонасының Татарстан Республикасының бер муниципаль берәмлеге чикләрендә булу шарты белән өч нөсхәдә тапшырыла. Санитар саклык зонасы ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек чикләрендә булган очракта, документлар, чикләрендә санитар саклык зонасы булган муниципаль берәмлекләр санына карап, дүрт һәм аннан да күбрәк нөсхәдә карау өчен кабул ителә.<br>6. Санитар саклык зонасы проектының барлык нөсхәләре тегелгән, саннар сугылган, мөрәҗәгать итүченең (физик затлар, шәхси эшкуарлар өчен) имзасы, җитәкченең имзасы һәм оешманың мөһере (юридик затлар өчен) белән беркетелгән булырга тиеш. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган башка органнар карамагында булган һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан су объектының санитар саклык зоналарының беренче поясы өчен җир кишәрлегенә хокуклар турында белешмәләр (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтендә);<br>2. Санитар саклык зонасы проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә);<br>3. Җир асты су объектына карата җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия күчермәсе (җир асты байлыкларыннан файдалану буенча<br>Татарстан Республикасы идарәсендә);<br>4. Файдалы казылма запаслары буенча җир асты су объектына карата җир асты сулары запасларын раслау турында территориаль комиссия беркетмәсе күчермәсе (Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча Татарстан Республикасы буенча идарәсендә);<br>5. Судан файдалану шартнамәсенең күчермәсе – өске су объектына карата (Су ресурслары федераль агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсенең | 2210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 177 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибенең 3, 4 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлегендә) | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителә | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 177 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибенең 8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.<br>Санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>1. Эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектының СанПиН 2.1.4.1110-02 билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>2. Мөрәҗәгать итүчедә әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларның булмавы;<br>3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр булуы | СанПиН 2.1.4.1110-02 кагыйдәләренең 1.12 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Рөхсәт алу буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры | Гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар пакеты кергән көннән алып бер көн эчендә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр | Катнашу урыны түбәндәгеләр белән җиһазландырылган:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен мебель белән;<br>Татарстан Республикасының дәүләт интеграцияле телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмат киоскысы белән;<br>мәгълүмати стендлары белән | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы; белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы; дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның мәгълүмат ресурсларында, бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүмат булуы;<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:<br>документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләр аларны тапшырганда чиратлар; дәүләт хезмәте күрсәтү | |

| | | |
|---|---|---|
| | срокларын бозу очракларының;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләре гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәтен күрсәткән граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәкләр аша күрсәтелми. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» мәгълүмат системасын кулланып, электрон документ рәвешендә җибәрелә ала. Бу очракта документлар Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле затның электрон имзасы белән имзалана. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау буенча дәүләт хезмәтен үтәү кысаларында түбәндәге процедуралар гамәлгә ашырыла:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү
2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;
4) санитар саклык зонасы проектын раслау яки санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турында карар кабул итү.
5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы №1 кушымтада тәкъдим ителә.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү.

Мөрәҗәгать итүче министрлыкның гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлегенә (алга таба – бүлек) шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша язмача дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча да.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә этәргеч булган рәсми мөрәҗәгатьне тапшыру мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча консультацияләр.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән кәгазьдә, электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, яисә почта аша заказлы почта юлламасы итеп, тапшыру турында белдереп, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны (алга таба — документларны) теркәп гариза тапшыра (җибәрә).

Гаризаны электрон формада җибәргән очракта, аңа сорала торган документларның сканер аша уздырылган күчермәләре теркәлә.

3.32. Эш башкару бүлеге белгече гариза һәм документларны кабул итә; гаризаны теркәү журналында терки (электрон рәвештә); мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы турында тамгалап, гаризаның күчермәсен тапшыра; гаризаны һәм документларны карау өчен бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, Бүлек җитәкчесенә тапшырылган документлар.

3.33. Җаваплы вазыйфаи затны билгеләү.

Бүлек җитәкчесе гаризаны һәм документларны карау өчен җаваплы башкаручы (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм тапшырылган материалларны аңа тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә тапшырылган документлар.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан су объектының санитар саклык зоналарының беренче поясы өчен җир кишәрлегенә хокуклар турында белешмәләр бирү турында – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә; санитар саклык зонасы проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсен бирү турында – Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенә; җир асты су объектына карата җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия күчермәсен бирү турында – Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча Татарстан Республикасы идарәсенә; файдалы казылма запаслары буенча җир асты су объектына карата җир асты сулары запасларын раслау турында территориаль комиссия беркетмәсе күчермәсен бирү турында – Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча Татарстан Республикасы буенча идарәсенә; судан файдалану шартнамәсенең күчермәсен бирү турында – өске су объектына карата – Су ресурслары федераль агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлегенә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ВЭХС аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматларны) законнарда билгеләнгән тәртиптә бирәләр.

3.5. санитар саклык зонасы проектын раслау яки санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турында карар кабул итү. Бүлек белгече:

тапшырылган документларны әлеге Регламентның 2.5 пунктында китерелгән документлар һәм материаллар исемлегенә туры килү-килмәве буенча тикшерә.

3.5.1. Әгәр тапшырылган документлар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килми икән, Бүлек белгече:

3.5.1.1. Санитар склык зонасы проектын караудан баш тарту турында хат әзерли һәм аны Бүлек җитәкчесенә килештерү өчен җибәрә;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар 3.3.3 процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: санитар саклык зонасы проектын карап тикшерүдән баш тарту турында Бүлек җитәкчесенә килештерү өчен җибәрелгән ике нөсхәдә хат проекты.

3.5.1.2. Бүлек җитәкчесе санитар саклык зонасы проектын караудан баш тарту турында хат проектын килештерә һәм аны Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгына (алга таба – Идарә) имзалау өчен җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе тарафыннан килештерелгән санитар саклык зонасы проектын караудан баш тарту турындагы хат проекты.

3.5.1.3. Идарә җитәкчесе санитар саклык зонасы проектын караудан баш тарту турында хат проектын килештерә һәм аны җир асты байлыкларыннан файдалану буенча министр урынбасарына (алга таба — министр урынбасары) имзалау өчен җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: санитар саклык зонасы проектын караудан баш тарту турында килештерелгән, министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән ике нөсхәдә хат проекты.

3.5.1.4. Министр урынбасары санитар саклык зонасы проектын караудан баш тарту турында ике нөсхәдәге хатка кул куя һәм эш башкару бүлегенә җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.5.1.2-3.5.1.4 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.1.1 пунктындагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: санитар саклык зонасы проектын карап тикшерүдән баш тарту турында имзаланган, эш башкару бүлегенә җибәрелгән ике нөсхәдәге хат.

3.5.1.5. Эш башкару бүлеге белгече:

хатны ведомствоара документлар әйләнеше системасында терки һәм аның беренче нөсхәсен гаризада күрсәтелгән адрес мөрәҗәгать итүчегә җибәрә; хатның икенче нөсхәсен саклау өчен Министрлык архивына җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: санитар саклык зонасы проектын карап тикшерүдән баш тарту турында теркәлгән хат, аның беренче нөсхәсе документлар

белән мөрәҗәгать итүчегә почта аша җибәрелгән, икенче нөсхәсе Министрлык архивына җибәрелгән.

3.5.2. Әгәр тапшырылган документлар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килә икән, Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын, тапшырылган документларның табигать саклау законнары таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерә.

3.5.3. Әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта:

3.5.3.1. санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турында хат проектын әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара гаризаларга җаваплар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турында Бүлек җитәкчесенә килештерү өчен җибәрелгән ике нөсхәдә хат проекты.

3.5.3.2. Бүлек җитәкчесе санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турында хат проектын килештерә һәм аны документлар белән бергә Идарә җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе тарафыннан килештерелгән санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турындагы хат проекты.

3.5.3.3. Идарә җитәкчесе санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турында хат проектын килештерә һәм аны документлар белән бергә министр урынбасарына имзалау өчен җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турында килештерелгән, министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән ике нөсхәдә хат проекты.

3.5.3.4. Министр урынбасары дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында ике нөсхәдә хатка кул куя һәм эш башкару бүлегенә җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.5.3.2-3.5.3.4. пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.1.1 пунктчасындагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: эш башкару бүлегенә җибәрелгән, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган ике нөсхәдәге хат.

3.5.3.5. Эш башкару бүлеге белгече:

хатны ведомствоара документлар әйләнеше системасында терки һәм аның беренче нөсхәсен гаризада күрсәтелгән адрес мөрәҗәгать итүчегә җибәрә; хатның икенче нөсхәсен саклау өчен Министрлык архивына җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: санитар саклык зонасы проектын раслаудан баш тарту турында теркәлгән хат, аның беренче нөсхәсе документлар белән мөрәҗәгать итүчегә почта аша җибәрелгән, икенче нөсхәсе Министрлык архивына җибәрелгән.

3.5.4. Әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, Бүлек белгече:

3.5.4.1. Боерык проектын әзерли;

Боерык проектын документлар белән бергә килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара гаризаларга җаваплар кергән көннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесенә килештерү өчен җибәрелгән документлар белән бергә Боерык проекты.

3.5.4.2. Бүлек җитәкчесе документларны һәм Боерык проектын карый, Боерык проектын килештерә һәм имзалау өчен Идарә җитәкчесенә юллый.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе тарафыннан килештерелгән, документлар белән бергә Идарә җитәкчесенә җибәрелгән Боерык проекты.

3.5.4.3. Идарә җитәкчесе документларны һәм Боерык проектын карый, Боерык проектын килештерә һәм министр урынбасарына җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә җитәкчесе тарафыннан килештерелгән, министр урынбасарына җибәрелгән Боерык проекты.

3.5.4.4. Министр урынбасары Боерык проектын килештерә һәм министрга җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.5.4.2. 3.5.4.4 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар 3.5.4.1 пунктча процедурасы тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Боерыкның килештерелгән проекты.

3.5.4.5. Министр Боерыкны имзалый һәм эш башкару бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: эш башкару бүлегенә җибәрелгән, имзаланган Боерык.

3.5.4.6. Эш башкару бүлеге белгече:

Боерыкны терки, Боерыкның 2 күчермәсен әзерли һәм таныклый.

Боерык Министрлык архивына тапшырыла, аның таныкланган күчермәләре Бүлеккә җибәрелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлык архивына җибәрелгән теркәлгән боерык, Боерыкның Бүлеккә җибәрелгән таныкланган күчермәләре.

3.5.4.7. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә таныкланган Боерык күчермәсен һәм санитар саклык зонасы проектының бер нөсхәсен бирә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән Боерыкның таныкланган күчермәсе һәм санитар саклык зонасы проектының бер нөсхәсе.

3.5.4.8. Бүлек белгече таныкланган Боерык күчермәсен һәм санитар саклык зонасы проектының бер нөсхәсен муниципаль берәмлек башкарма комитетына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Боерыкка кул куйганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль берәмлек башкарма комитетына җибәрелгән Боерыкның таныкланган күчермәсе һәм санитар саклык зонасы проектының бер нөсхәсе.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшереп тору түбәндәгеләрдән гыйбарәт: гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, шикаятьләрне карау, тикшерүләр уздыру, карарлар кабул итү һәм гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата карарлар әзерләү.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларның проектларына экспертиза уздыру. Экспертизаның нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;
- эшчәнлек алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерүләр;
- билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерү барышында дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) карала. Планнан тыш тикшерүләр мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору максатларында, дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә тапшырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген контрольдә тоту Бүлек җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Министр (министр урынбасары) мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында каралуын тикшерүдә тота.

4.4. Регламент үтәлешенә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольдә тоту Министрлыкка мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауны) һәм карарларга югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять белдерү юлы белән дә гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затлар Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә Министрлыктагы дәүләт хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарга карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең үтенечен теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тарту;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять

белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять үзен тапшырган, дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча министр түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка формаларда да;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге Регламентның 5.7 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача формада яки, аның ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүче санитар саклык зонасы проектын раслау турында гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 п. нигезендә документлар тапшыра

Гариза, документлар

Эш башкару бүлеге белгече

Гариза һәм документларны кабул итү, теркәү

1 көн

Теркәлгән документлар

Бүлек җитәкчесе

Билгеләнгән җаваплы башкаручы

Җаваплы башкаручыны билгеләү һәм тиешле карар кабул итү өчен гаризаны тапшыра

1 көн

Бүлек белгече

Электрон рәвештә ВЭХС аша гаризалар җибәрә

1 көн

Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча ТР идарәсе

Күчемсез мөлкәтнең бердәм реестрыннан санитар саклык зонасының беренче поясы буенча белешмәләр бирү турында гариза

Санитар саклык зонасы проектының санитар нормаларга туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсен бирү турында гариза

Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия күчермәсен бирү турында гариза һәм беркетмә күчермәсе

Бүлек белгече

Судан файдалану шартнамәсе күчермәсен бирү турында гариза (өске су объекты өчен)

туры килмәгәндә

Бүлек белгече

Документларны тикшерә 1 көн

Тикшерелгән документлар

документлар

документлар туры килсә

Проектны раслаудан баш тарту турында хат проектын әзерли

Хат проекты

Бүлек белгече

Санитар саклык зонасы

Бүлек җитәкчесе

Документларны табигать саклау законнарына туры килү-килмәве буенча тикшерә. Баш тарту өчен сәбәпләр булмаса, проектны раслау турында Боерык проекты әзерли

Тикшерү, хәбәр итү, Боерык проектын тикшерү

ССЗ

Хат проектын килештерә 1 көн

Килештерелгән хат проекты

Бүлек җитәкчесе

Идарә җитәкчесе


Боерык проектын килештерә

Килештерелгән Боерык проекты

Хат проектын килештерә 1 көн

Килештерелгән хат проекты

Идарә җитәкчесе


1 көн
Килештерелгән Боерык проекты
Боерык проектын министр урынбасары аша килештерә
Рөхсәт бирүдән баш тарту турында хатка кул куя 1 көн
Имзаланган хат
Боерык проектын килештерә
1 көн
Килештерелгән Боерык проекты
Эш башкару бүлеге белгече
Министр
Боерыкны имзалый
1 көн
Имзаланган Боерык
Хатны терки һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә
1 көн
Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хат
Бүлек белгече
Мөрәҗәгать итүчегә боерык күчермәсен бирә
1 көн
Бирелгән Боерык күчермәсе

Министр урынбасары
Т. М. Акчурин

Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы
А.Е. Никулин

Минерал-чимал идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы
С.Г. Кулешов

Гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе Т.Л. Васильева

Гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе урынбасары Н.В. Чуйкова

Корректор
З.Х. Рәхмәтуллина